ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2023 с.Старое Дрожжаное №52

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына таянып (15.11.2022 ел, № 1214 редакциясендә), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 августындагы 375 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**түбәндәге эчтәлекле 1.1** пункт өстәргә:

«1.1. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан 35 яшькә кадәрге, беренче тапкыр көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, аспирантура программалары буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы), һәм һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга

калмыйча, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә, хезмәт шартнамәсе буенча оешмага эшкә алынган зат таныла.»;

**5 нче пунктта** «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга (PRAVO/TARSTAN.RU).

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов